ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ «ИННОПОЛИС ШӘҺӘРЕ» МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕНЕҢ ИЛЛЕ ИКЕНЧЕ ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ

1нче номерлы КАРАР

«11» август 2021 ел, Иннополис шәһәре

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының «Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлеге гражданнарының XLI җыенында «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының «Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясендә җир салымы турында» 2019 елның 18 декабрендәге 3 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының «Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Россия Федерациясе Салым кодексының 31 бүлеге нигезендә,

«Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлеге гражданнар җыены
КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының «Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлегенең 3 номерлы XLI гражданнар җыенының «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы «Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясендә җир салымы турында» 2019 елның 18 декабрендәге карарына үзгәрешләр кертергә:

1.1. карарның 4.2 пунктындагы 4.2 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.2.3. Татарстан Республикасы бюджетыннан һәм/яки Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы «Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлеге бюджетыннан финанслана торган коммерцияле булмаган оешмаларга – гомуми файдаланудагы җир кишәрлекләренә карата, мәдәният һәм ял паркларын, мәдәни үсеш куллану рөхсәт ителгән төрләргә карата.

2. Әлеге карар 1922 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Интернет челтәрендә Югары Ослан муниципаль районының мәгълүмат сайтында (http://verhniy-uslon.tatarstan.ru/), шулай ук Иннополис шәһәре мэриясе бинасында урнашкан махсус мәгълүмат стендында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен үзем контрольдә тотам.

Рәислек итүче,
Иннополис шәһәре мэры Р. Р. Шагалиев